СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2024 г. Агрыз № 40-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 21.03.2023 елның 27-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендәге күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 22.07.2008 елның 159-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне читләштерү турында Татарстан Республикасы муниципержә муниципаль районы Советының 21.03.2023 елның 27-4 карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба — нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 1 пунктчасында «ике ел» сүзләрен «бер ел» сүзләренә алмаштырырга;
- Нигезләмәнең 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Район Советы муниципаль милекне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарларда арендаторларның, әлеге Нигезләмәнең 3 бүлегендә билгеләнгән шартларны үтәп, арендага бирелә торган мөлкәт сатып алуга өстенлекле хокукы булуны күздә тота»;
- Нигезләмәнең 4.2 пунктында «Орган» сүзен «Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы»на алмаштырырга;
- Нигезләмәнең 4.10 пунктында «Орган» сүзен «район Советы»на алмаштырырга;
- Нигезләмәнең 8.4 пунктында «Орган» сүзен «Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы»на алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев